РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА КИЧКАЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423038, с. Кичкальня, ул. Школьная, д.11
Тел./факс: 8-(84345) 4-42-30
Email: Kichk.Nur@tatar.ru,
ОКПО 27922845, ОГРН 1021605352460,0 ОКАТО 92246842000
ИНН/КПП 1632001554/163201001, ОКТМО 92646442

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЧЫТКАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423038, Кычытканлы авылы, Мәктәп ур, 11 йорт
Тел./факс: 8-(84345) 4-42-30
Email: Kichk.Nur@tatar.ru
ОКПО 27922845, ОГРН 1021605352460,0 ОКАТО 92246842000
ИНН/КПП 1632001554/163201001, ОКТМО 92646442

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Кычытканлы ав. КАРАР

«08» ноябрь 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кычытканлы авылы Мәктәп урамы 8нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында Көнчыгыш, Елга аръягы, Овражная урамында яшәүче гражданар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2021 елның 19 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Кычытканлы авылы Мәктәп урамы 8нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында Болынлык урамы, Новаторлар урамы, Мәктәп урамындагы йортларда яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кычытканлы авылы Мәктәп урамы 8нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында Көнбатыш урамы, Яңа урам, 1нче Стаханов, 2нче Стаханов урамнарындагы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылында яшәүчеләрнең гражданнар җыенын үткәрү өчен исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре белән Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы һәм Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Башкарма комитеты тәэмин итә.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән сезонлы карап тоту (Кычытканлы авылы юлларын кардан чистарту өчен махсус техника яллау).

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров